**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ТУРАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Центральная, д.11А,
с. Тураево, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423627

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Үзәк, 11А йорт,
Турай авылы, Менделеевск районы,
Татарстан Республикасы, 423627

Тел. (факс): (85549) 2-73-31
e-mail: Tur.Men@tatar.ru

Р Е Ш Е Н И Е КАРАР

№ 80 14.03.2023 ел

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең 2022 елның 22 мартындагы 52 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 21 статьясындагы 13 пунктының 2,3 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«Бюджет турындагы законда (карарда) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, Җирлек башкарма комитеты карарлары нигезендә юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга грантларны субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган субсидияләр рәвешендә, бүлеп бирүгә бюджет ассигнованиеләре каралырга мөмкин.

Әлеге тәртип әлеге пунктның беренче абзацында каралган карарлар белән билгеләнмәгән булса, күрсәтелгән субсидияләрне федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетлардан бирү тәртибе тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы дәүләт

хакимиятенең югары башкарма органының, муниципаль хокукый актларның Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләргә туры килергә тиешле норматив хокукый актлары белән билгеләнә.”;

1.2. Нигезләмәнең 50 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«3. Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм аңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә.

Бюджет акчаларын алучы муниципаль контрактлар, физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр башка хокукый акт яисә закон, килешү нигезендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы үзенә җиткерелгән бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитлары һәм кабул ителгән, әмма үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре арасындагы аермадан артмаган күләмдә яңа бюджет йөкләмәләре ала.

Бюджет акчаларын алучы муниципаль контрактлар төзи, бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогы чикләрендә мондый муниципаль контрактлар, башка килешүләр буенча бурычларны үтәүне күздә тота торган, РФнең Бюджет кодексы нигезләмәләрендә бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка федераль законнар нигезләмәләрендә каралган очракларда. Муниципаль контрактлар, башка килешүләр төзү өчен билгеләнгән күрсәтелгән нигезләмәләр элегрәк төзелгән муниципаль контрактларга, башка килешүләргә үзгәрешләр кертелгәндә дә кулланыла.».

2. Әлеге карарны Турай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru « Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Турай авыл җирлеге Советы урынбасары Р.Р.Шәймөхәммәтов